# ТУГАН ҖИРЕМ, МӘКТӘБЕМ, ҺӨНӘРИ ЭШЧӘНЛЕГЕМ



*Баһавиева Рәмзия Габдуллаҗан кызы*
*13 август, 1960 нчы ел*
*КГПУ, 1996 нчы ел.*
*1нче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Эш стажы - 38 ел*
*Педагогик стаж - 24ел*



*Авыл - туган җир. Минем өчен иң кадерле, иң гүзәл бишек ул. Мине кадерләп, назлап, саф һавасын сулатып, хезмәткә, сабырлыкка өйрәтеп үстергән туган авылым - Битаман. Авылымның гүзәллегенә мин кечкенәдән гашыйк. Гомер үткән саен аны яратуым арта бара. Җәе җитсә, табигатьнең гүзәллегенә сокланып, бай урманнарында җиләк җыям, яшел болыннарында хуш исле печәннәр исним, шифалы елгасында коенам, уңдырышлы җирендә татлы җимешләр үстерәм.*



*Күзе җитсә, мәктәбемне сагынып кайтып, балаларга белем бирә башлыйм. Салкын буранлы кышын да күтеп алам. Кояшлы язы җитсә, сабыйларча шатланып, авыр хезмәтемә нәтиҗә ясыйм.*



*Балаларны ихлас күңелдән ярату һөнәр сайларга да ярдәм итте. Очар кошлар күкне сагынгандай, көн саен мәктәбемә ашыгам. Егерме ел сәбәпсез бер көн эш калдырмыйча, хастәханә ялы да алмыйча ,хезмәтемне Битаман мәктәбендә давам итәм.*



*Төзек холыклы, күркәм гадәтле, аңлы һәм укымышлы кешеләр тәрбияләүне максат итеп куеп, һаман алга таба атладым.*



*Мине мәктәптә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп билгеләделәр: көне-төне эзләнергә, яңалыклар уйлап табарга туры килде.*



*Яшь буында милли үзаң, әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү, аларга халкыбызның рухи мирасын җиткерү, үз милләте, халкы белән горурлану хисе тәрбияләү - минем бурычыма әйләнде.*



*Укучылар узем иҗат иткән «Озату» куренешен сәхнәләштерәләр.*



*Сугыш чоры балалары белән “Әле дә сыкрый, әрни йөрәкләр” диган очрашу үткәрдем.*



*2003 нчы елны мин беренче категорияле тәрбияче булдым.*




*Укучыларыма биргән матур дәресләр, алар белән үткәргән чаралар ярдәмендә мин “Өлкән укытучы” исеменә лаек булдым.*




*2008 нче елда беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы булдым.*



*Тормышымның һәр көн–мизгеленә җаным-тәнем белән куанып яшим.*





*Авыл, мәдәният йорты белән тыгыз элемтәдә торам. Буш вакытларымда үзешчән сәнгатьтә катнашам: төрле милләт биюләрен башкарам, күңелле кичәләр алып барам.*



*Укытучылар коллективы белән ел саен концерт куйдык*



*Тату гаилә корып яшим. Мәдәният йортында үткәргән чараларда да гаиләбез белән бергәләп катнашабыз.*




*“Мәхәббәт чишмәсе” спектаклендә Гайни әби ролен башкарам.*



*Укучыларым белән куңелле кичәләр оештыру – минем яраткан шөгылемә әйләнде.*




*Мәктәпне тәмамлаучылар белән очрашу кичәләре алып бардым.*




*Авыл җирлегендәге һөнәр ияләре белән очрашу кичәсе оештырдым*




*Очрашу кичәсенә классташларым килде.*



*Укучыларым белән сугыш ветераны Мансур абыйны 90 яшьлеге белән котладык.*



*Район күләмендәге ярышларда катнашып призлы урыннар алдым.”Кросс-наций” – 1 нче урын*

# Минем ирешкән уңышларым




ГРАМОТА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАМОТА
ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА
МАКТАУ ГРАМОТАСЫ
ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА


III
МЕСТО
Грамота
НАГРАЖДАЕТСЯ


ГРАМОТА
НАГРАЖДАЕТСЯ


Грамота
НАГРАЖДАЕТСЯ


Почетная грамота


Зирэк Тиен


Зирэк Тиен



*2015 нче елда лаеклы ялга чыгып бәйрәм үткәрдем.*



*Шатлыгымны уртаклашырга хезмәттәшләрем җыелды*



*Хәзерге вакытта  минем дүрт оныгым бар.*



*Быел 5 нче класс укучыларын җитәклим*

Нигә мин сайладым укытучы эшен?
Яшәргә, эшләргә, яшнәтеп яшен!
Сорыйм алтмышка  җиткәндә дә яшем:
"Бир тагын ходай, сабырлык көчен!"